БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 03 2025 ел № 124

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының кайбер норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 2024 елның 12 мартындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 288 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 01 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында»271 номерлы карарына, карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 гыйнварындагы «Гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында» 06 номерлы карарының» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 01сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» 271 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» 06 номерлы карарының» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 4.2 пунктының 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлектә тоту;».

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 01 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында»гы 272 номерлы карарына, карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 гыйнварындагы «Татарстан

Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» 06 номерлы карарының» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.».

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021елның 01 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында» 272 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнар оборонасы штабы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.1. 2.2 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлектә тоту;».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов